# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлегенең Кормаш авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**30 март 2024 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгынын 20.03.2024 ел 1 нче номерлы "«Шәрләрәмә авыл җирлеге Кормаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Кормаш торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Кормаш торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында" карары нигезендә 2024 елның 30 мартында 9.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән протокол төзелде. Гражданнар җыенына түбәндәге сораулар тәкъдим ителде.

«Шәрләрәмә авыл җирлеге Кормаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Кормаш торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1. Кормаш торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны вак таш белән каплауны оештыру(вак таш ташу)»;

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 31 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 22 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 22 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл жирлегенең Кормаш авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. Түбәндәге сораулар буенча :

«Шәрләрәмә авыл җирлеге Кормаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Кормаш торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 2

номерлы гражданнар жыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1. Кормаш торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны вак таш белән каплауны оештыру(вак таш ташу)карарны кабул ителгән дип санарга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Шәрләрәмә авыл җирлегенең Кормаш мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Н.Н.Хуҗина